# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 26.10.2024 ел

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Әлкәй авыл
җирлеге Кызыл Сукачы торак пунктында гражданнардан
үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүг буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- территорияләрне төзекләндерүне оештыру (Кызыл Сукачы авылында юлларны кардан чистарту);
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту (зират коймасы, материал сатып алу һәм урнаштыру).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Әлкәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы С.З.Зиннурова